ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«21» февраль 2024 ел** **№ 139**

**«2015-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 декабрендәге 1243 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү максатыннан һәм «2015-2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 сентябрендәге 577 номерлы Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 декабрендәге 1243 номерлы карарына (01.06.2016 №653, 17.09.2018 № 859, 18.03.2019 № 140, 11.09.2019 № 716, 2020.07.2020 №537, 24.08.2021 №605, 12.10.2021 №852, 26.07.2022 №698 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «2015-2025 еллар» сүзләрен «2015-2026 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru/).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.02.2024 ел, № 139 карарына
кушымта

«2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы

**Муниципаль программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (исеме, хокукый актның номеры һәм датасы) | 1. «2021 - 2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган 2021 - 2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы;<br>2. «Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе;<br>3. 2021 елның 14 декабрендәге 475-р номерлы Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы күрсәтмәсе белән расланган 2021 - 2024 елларга халыкны коррупциягә каршы агарту программасы;<br>4. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;<br>5. «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;<br>6. «2015 - 2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>7. Арча муниципаль районы Уставы. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш комиссиясе |
| Программаны башкаручылар | 1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары;<br>2.Арча район Советы (килешү буенча);<br>3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы;<br>3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>4. Арча районы прокуратурасы (килешү буенча);<br>5. «Арча район үзәк хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча);<br>6. Шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары. |

| | |
|---|---|
| Программаның максаты | Коррупция дәрәҗәсен киметү, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән җәмгыять тормышының һәм эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә коррупция барлыкка килү сәбәпләрен бетерү. |
| Программаның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы инструментлар һәм механизмнарны, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;<br>2. Коррупциягә каршы көрәш пропагандасын активлаштыру, граждан җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;<br>3. Дәүләт һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;<br>4. Эшкуарлык (бизнес) өчен административ басымны эзлекле киметү;<br>5. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән коррупция факторларын ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү;<br>6. Коррупция торышын мониторинг тикшеренүләре уздыру юлы белән бәяләү;<br>7. Дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачыклыгын, аңлаешлылыгын тәэмин итү, аларның граждан җәмгыяте белән элемтә идарәсе, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;<br>8. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү;<br>9. Муниципаль хакимият органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>10. Көнкүреш коррупциясен киметү чараларын көчәйтү;<br>11. Дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы торучанлыгын стимуллаштыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы һәм этаплары | I этап: 2015 - 2023 еллар;<br>II этап: 2024 - 2026 еллар |

<table>
<tr><td>Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары<br>.</td><td>Чаралар җирле үзидарә органнарын тотуга каралган муниципаль берәмлек бюджеты акчалары чикләрендә уздырыла:<br><table>
<tr><th>Ел</th><th>ТР Арча муниципаль районының җирле бюджеты акчалары</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>35,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>40,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>65,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>75,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>80,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>825,0</td></tr>
</table>
I этап: 585,0 мең сум;<br>II этап: 240,0 мең сум.<br>Искәрмә: финанслау күләме фараз характерында һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td>Муниципаль программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:<br>1. бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану;<br>2. коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү;<br>3. һөнәри белем бирү дәрәҗәсен һәм муниципаль хезмәткәрләрне әзерләү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыручы</td><td>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ</td></tr>
</table>

## 1. Аңлатма язуы

Коррупция дәүләт һәм җәмгыятьнең социаль-икътисади үсешенә тискәре йогынты ясый, конкурентлыкка сәләтле икътисадны формалаштыруда киртә булып тора, халыкның иминлегенә, граждан җәмгыятенең үсешенә комачаулый. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәте муниципаль дәрәҗәдә нормага салу һәм хокук куллану эшен камилләштерү, районда коррупциягә каршы тору чараларын активлаштыру белән характерлана. Эш коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарның федераль һәм республика дәрәҗәсендә үзгәрүенә бәйле рәвештә аларны үзгәртү буенча башкарыла.

## 2. Муниципаль программаның төп максатлары, бурычлары

Программаның өстенлекләре «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә (алга таба – Стратегия-2030), «Россия Федерациясенең

милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясенә (алга таба – Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе), «2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган 2021-2024 елларга коррупциягә каршы торуның милли планына туры килә.

Программа коррупция барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау һәм бетерүгә (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә каршы торырлык шартлар тудыруга, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп булмаслык мөнәсәбәт булдыруга юнәлтелгән.

Программаның максаты - коррупция дәрәҗәсен киметү, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә коррупция барлыкка килү сәбәпләрен бетерү.

Программаның бурычлары:

1) коррупциягә каршы көрәш инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;

2) коррупциягә каршы тору һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмат һәм граждан җәмгыятенең башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;

3) муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

4) эшкуарлык (бизнес) өчен административ басымны киметү.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру срогы:

I этап: 2015 - 2023 еллар;

II этап: 2024 - 2026 еллар.

Программаның төп максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, шулай ук Программада каралган чараларны финанслау күләмнәре Программага кушымтада бирелде.

## 3. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның үтәлешен планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм гомуми контрольне Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш комиссиясе гамәлгә ашыра, ул ел саен Программа чараларының максатчан күрсәткечләрен һәм чыгымнарын, Программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын ачыклый, Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, чараларны үтәү өчен җаваплы учреждениеләрдән һәм оешмалардан Программа үтәлешенең барышы турында белешмәләр соратып ала.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларын җаваплы башкаручы белән килештереп яисә Арча муниципаль районы башлыгы - Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш комиссиясе рәисе- күрсәтмәләрен үтәү буенча билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

2026 елга Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешү мөмкинлеген бирәчәк:

коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген арттыру;

Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы эшчәнлегендә җәмәгатьчелекнең ролен күтәрү;

җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп булмаслык мөнәсәбәт формалаштыру.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның икътисади нәтиҗәсе Арча муниципаль

районының җәлеп итүчәнлек имиджын формалаштыру, шул исәптән инвестициячел җәлеп итүчәнлеге, эшкуарлык активлыгын күтәрү, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупция чагылышларына бәйле бюджет югалтуларын киметүдә күзәтелергә мөмкин.

Программада эшчәнлекнең нәтиҗәләрен характерлаучы индикаторлар һәм күрсәткечләр системасы кулланыла. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү аны гамәлгә ашыруның бөтен чорында 2026 елга кадәр Программаны үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча кушымтада китерелгән күрсәткечләргә ирешүне исәпкә алып уздырыла.

*Муниципаль программага кушымта*

# «2015 - 2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, II этабы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү срогы | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторны үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткечләре | | | | Финанслау (Арча муниципаль районы бюджеты акчасы хисабына), мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 ел (төп) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2024 ел | 2025 ел | 20 26 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| **Максат: коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру** | | | | | | | | | | | |
| **1 бурыч Коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү** | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Район җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын эшләү һәм федераль, республика законнарын үтәүгә һәм ТРда гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә коррупциягә каршы тору өлкәсендә район җирле үзидарә органнарының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары (алга таба-ҖҮО) | 2024 – 2026 еллар | Федераль һәм республика законнарына туры китерелгән коррупциягә каршы тору өлкәсендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары өлеше | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.2. «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указына һәм Указы белән гражданнарга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдергән һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү турында" 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына ярашлы рәвештә, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча район җирле үзидарә органнары бүлекчәләренең (коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы кадрлар хезмәте вазыйфаи | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | Коррупциягә каршы торуның оештыру һәм хокукый чараларын, шул исәптән эчке контроль һәм кадрлар сәясәтендә коррупциягә каршы механизмны кабул итүнең тулылыгы | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| затларының) нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| 1.2.1. Муниципаль хезмәт турында, коррупциягә каршы тору хакында законнарның таләпләрен үтәп, хезмәткәрләрнең, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында: муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне үткәрү Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозулар турында ТР Прокуратурасы органнарына хәбәр итү | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.2. «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» Федераль салым хезмәтенең белешмәләр базаларыннан файдаланып, муниципаль хезмәт турындагы законнарда, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлегендә катнашу предметына каралган чикләүләр һәм тыюларның район муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан үтәлешенә тикшерү үткәрү (елына кимендә бер тапкыр) | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.2.3. Эшкә алучы вәкиленә законнарда билгеләнгән тәртиптә керә торган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләре каршылыгы булу яисә барлыкка килү мөмкинлеге турында мәгълүматка тикшерү үткәрү | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.2.4. Эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиле билгеләгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында белешмәләрне тикшерү | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.2.5. Район муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырылганда барлыкка килә торган коррупция куркынычларын бәяләү һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә төгәллекләр кертү | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.2.6.Махсус программа тәэминаты базасында эшләнгән компьютер | Кадрлар хезмәтенең | 2024 – 2026 | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| программаларын коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлекчәләре (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затлар) эшчәнлегендә түбәндәге максатларда куллану: тиешле исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы затлар һәм күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, күчемсез милек (шул исәптән чит илләрдә), транспорт чаралары, счетлар, кредитлар турында мәгълүмат базаларын кулланып, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны мониторинглау һәм автоматлаштырылган анализлау, гражданлык-хокукый шартнамә (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында оешмада вазыйфа биләүгә яки әлеге оешмада эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтү) хезмәт килешүе шартларында, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен җыю, системалаштыру һәм карау | коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | еллар | | | | | | | | | |
| 1.2.7. Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләренә анализ ясау һәм мондый хезмәткә кергәндә тапшырыла торган анкеталардагы белешмәләрне актуальләштерү, аларның туганнары (абый-апа, эне-сеңел, ир яки хатынның абый-апалары, эне-сеңелләре) турында, мөмкин булган мәнфәгатьләр каршылыгын ачыклау максатларында актуальләштерү | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.3. Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәшне координацияләү комиссиясе эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү, шул исәптән алар эшчәнлегенә иҗтимагый советларны һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итү юлы белән | Башлык ярдәмчесе | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм федераль һәм республика законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиянең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | Район башлыгы урынбасары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.5. Арча муниципаль районы сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында законнар белән билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә мәгълүмат урнаштыру | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җаваплы вазыйфаи затлары. | | | | | | | | | | |
| 1.6. Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ҖҮО эшчәнлеген тәэмин итүдә методик һәм гамәли ярдәм | Кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары. | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.7.Ведомство карамагындагы учреждениеләр уставларына үзгәрешләр кертү эшен оештыру, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы нормалар өлешендә оештыру-идарә итү, административ-хуҗалык функцияләре бирелгән ведомство карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре белән хезмәт килешүләре | Ведомство карамагындагы учреждениеләр булган ҖҮО | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.8. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуына мониторинг ясау | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.9. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чараларны күрү бурычын үтәүне тәэмин итү максатларында, коррупцияне кисәтү, шул исәптән мәнфәгатьләр каршылыгын ачыклау, кисәтү һәм җайга салу буенча районның җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар белән эш алып бару | ҖҮО (килешү буенча) | 2024 – 2026 еллар | мондый оешмаларның гомуми саныннан ведомство буйсынуындагы тикшерелгән оешмалар өлеше, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 1.10. Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш комиссияләренең еллык эш планнарын раслау һәм үтәү | Башлык ярдәмчесе | 2024 – 2026 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | процент | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |
| **2 бурыч. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү, коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү** | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру һәм күрсәтелгән экспертизаны уздыру нәтиҗәләрен гомумиләштерү өчен шартлар тәэмин итү | Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча җаваплы затлар | 2024 – 2026 еллар | Коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән закон һәм башка норматив хокукый актларның аларның проектларын эшләү стадиясендә өлеше, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 2.2. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен кирәкле шартлар тудыру | Норматив хокукый актларга һәм | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча җаваплы затлар | | | | | | | | | | |
| **3 нче бурыч Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү** | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Арча муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә мониторинг ясау | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Социологик сораштырулар оештыру буенча дәүләт йөкләмәсен үтәүнең тулылыгы - процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 3.2. Коррупциячел факторларны һәм гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы чараларны максатчан төркемнәр арасында тармак тикшерүләре үткәрү һәм узган тикшерүләрнең нәтиҗәләрен бастырып чыгару | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 3.3. Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга гражданнар җәмгыяте институтларының җәлеп ителүенә; коррупция темасына район массакүләм мәгълүмат чараларында материалларга мониторинг ясау | Арча районы Иҗтимагый Советы | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| **4 бурыч. Коррупциягә каршы аңлату эшләрен активлаштыру һәм коррупциягә каршы пропаганда, кадрларны, гражданнар җәмгыятенең матди, мәгълүмат һәм башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү** | | | | | | | | | | | |
| 4.1. Коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналарны укыту программаларына кертеп, районның муниципаль хезмәткәрләрен квалификация күтәрү программалары буенча укытуны оештыру | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары (алга таба-ҖҮО) | 2024 – 2026 еллар | Квалификация күтәрү узган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләренең өлеше, процент | процент | 33 | 33 | 33 | 33 | - | - | - |
| 4.1.1. Ел саен коррупциягә каршы торуда катнашучы муниципаль хезмәткәрләрнең махсус квалификацияләрен күтәрү | Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы башлык ярдәмчесе, кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 4.1.2. Муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләү өчен муниципаль хезмәткә беренче тапкыр килгән муниципаль хезмәткәрләрне коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар булган укыту программалары буенча (укыту программасы буенча кимендә 8 академик сәгать) махсуслаштырылган укырга җибәрү | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 4.1.3. Муниципаль хезмәткәрләрнең, вазыйфаи бурычларына муниципаль | ҖҮО (килешү буенча) | 2024 – 2026 | | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны уздыруда катнашу кирәк торган хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тору өлкәсендә ел саен квалификация күтәрүне тәэмин итү | | еллар | | | | | | | | | |
| 4.2. Коррупциягә каршы торуда катнашучы муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләренең һәм башка затларның квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән кыска сроклы махсуслаштырылган семинарлар оештыру һәм үткәрү | Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы башлык ярдәмчесе, кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2024 – 2026 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | шартлы берәмлекләр | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - |
| 4.3. Ведомство карамагындагы учреждениеләрдә коррупциягә каршы тору буенча методик мәгълүмати материаллар эшләү, тарату һәм актуальләштерү | Ведомство карамагындагы учреждениеләр булган ҖҮО | 2024 – 2026 еллар | ҖҮО коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән тәэмин итү | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 4.4. Районның җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар хезмәткәрләрендә коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру эшен гамәлгә ашыру, шул исәптән чикләүләрне, тыюларны үтәү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча эш оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү, әлеге эшкә коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый советларны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм башка институтларны җәлеп итү | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль оешмалар өлеше | процент | 50 | 50 | 50 | 50 | - | - | - |
| 4.4.1. Арча МР Иҗтимагый Советы утырышларында, Арча район Советы утырышларында, гражданнар җыеннарында коррупциягә каршы тору программаларын гамәлгә ашыру турында хисапларны карау | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 4.4.2. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләрне, тыюларны үтәү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча эш оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән бүләк бирү һәм алуга кагылышлы чикләүләр, әлеге эшкә Арча МР Иҗтимагый Советын, коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый берләшмәләрне һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 4.4.3. Коррупциягә каршы тору өлкәсендәге халыкара актларның ришвәт бирү яки ришвәт алу вәгъдәсе һәм ришвәт бирү яки ришвәт алу тәкъдиме турындагы нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ришвәт бирүне вәгъдә итү яки тәкъдим итү яисә ришвәт алуга ризалык буларак кабул ителергә мөмкин булган үз-үзен тотышын булдырмау буенча эш оештыру | | | | | | | | | | | |
| 4.5. Коррупциягә каршы юнәлештәге чараларны мәгълүмати тәэмин итүне, җәмгыятьтә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча агарту эшен оештыру | "ТАТМЕДИА" АҖнең «Арча-информ» филиалы | 2024 – 2026 еллар | Коррупциягә каршы укытуга һәм коррупциягә каршы пропагандага юнәлдерелгән үткәрелгән чараларның бер елга планлаштырылган гомуми саныннан өлеше, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 4.6. Коррупция темасына массакүләм мәгълүмат чаралары материалларына мониторинг ясау | Башлык ярдәмчесе | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 4.7. «Илемнең киләчәге - минем кулымда!», «Коррупциягә "Юк" дип әйтик!» темасына милли мәктәпләр укучыларының иҗади эшләре һәм балалар рәсемнәре, «Намуслы яшәргә кирәк!», «Закон сагында, коррупциягә каршы» һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында иҗади эшләр республика конкурсы үткәрү | Арча МР башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | 45,0 | 45,0 | 45,0 |
| 4.8. ҖҮО һәм муниципаль учреждениеләр өчен коррупциягә каршы темага социаль баннерлар әзерләү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Куелган баннерлар саны | шартлы берәмлекләр | 2 | 2 | 2 | 2 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| **5 нче бурыч Дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, халык өчен һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү, аларның граждан җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру** | | | | | | | | | | | |
| 5.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ТР Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсе, процент | процент | 90 | 90 | 90 | 90 | - | - | - |
| 5.2. Административ регламентлардан файдаланганда муниципаль хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән хезмәтләрдән соңгы файдаланучыларны сораштыру юлы белән мониторинг үткәрү: | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 5.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын камилләштерү, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Тору урыны буенча «Бер тәрәзә» принцибы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алырлык гражданнар өлеше, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, процент<br>Бер хезмәт алу өчен җирле үзидарә органнарында бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләре мөрәҗәгатьләренең уртача саны | процент | 90 | 90 | 90 | 90 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.4. «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларының бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 04 апрелендәге 225 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән законнар һәм таләпләр нигезендә Арча муниципаль районы рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлеген тулыландыруны оештыру | Башлык ярдәмчесе, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары. | 2024 – 2026 еллар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 04 апрелендәге 225 номерлы карары белән билгеләнгән законнар һәм таләпләр нигезендә үзенең рәсми сайтларын мәгълүмат белән тулыландыруны тәэмин итүче ҖҮО өлеше, процент | процент | 90 | 90 | 90 | 90 | - | - | - |
| 5.5. "Ышаныч телефоны", "кайнар линия", интернет-кабул итү каналлары аша аларга мәгълүм коррупция фактлары, аларны башкаруга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүмат каналлары эшчәнлеген тәэмин итү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачыклыгын, һәркем өчен ачык булуын тәэмин итүгә, аларның гражданнар җәмгыяте белән элемтәсен ныгытуга, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга, бер елга планлаштырылган гомуми саннан, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 5.6. Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру һәм коррупциянең торышы турында еллык хисапларны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм интернет-сайтларда урнаштыруны гамәлгә ашыру | Башлык ярдәмчесе | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 5.7. Массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм аның нәтиҗәләрен Арча МРда коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе утырышында тикшерү, районның вазыйфаи затлары эшчәнлегендә коррупция чагылышлары турында мәгълүматка квартал саен мониторинг ясау | Арча муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 5.8. Коррупциягә каршы тору буенча ҖҮО тарафыннан күрелә торган чаралар турында массакүләм мәгълүмат чараларына җиткерү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 5.9. Мәгълүмат стендларын рәсмиләштерү һәм актуальләштерү, районның рәсми сайтларының «Коррупциягә каршы тору» бүлеген һәм ҖҮО һәм муниципаль учреждениеләрдә коррупциягә каршы эчтәлектәге мәгълүматны тапшыруның башка формаларын рәсмиләштерү һәм актуальләштерү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| **6 нче бурыч.Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү** | | | | | | | | | | | |
| 6.1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алуларны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән гамәлгә | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының | 2024 – 2026 еллар | Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ашырыла торган сатып алуларның ачыклыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү буенча чаралар уздыру, шулай ук сатып алуларда катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | икътисад һәм финанс бүлеге, ЖҮО | | сатып алуны гамәлгә ашыру эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән ЖҮО өлеше, процент | | | | | | | | |
| 6.2. «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау, коррупциячел куркынычларны ачыклау һәм минимальләштерү максатларында ведомствога караган оешмаларның сатып алуларына анализ ясау | Арча МР финанс-бюджет палатасы, Арча МР контроль-хисап палатасы | 2024 – 2026 еллар | Бер елга планлаштырылган тикшерүләрнең гомуми санынннан алып үткәрелгән тикшерүләр өлеше, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| **7 нче бурыч. Эшмәкәрлеккә (бизнес-структураларга) административ басымны эзлекле рәвештә киметү** | | | | | | | | | | | |
| 7.1. Эшмәкәрләр белән киңәшмәләр үткәрү, булган административ киртәләр һәм җирле үзидарә, хокук саклау органнарының бизнес-структураларга тискәре йогынтысы мәсьәләләрен карау, шулай ук (кирәк булганда) эшмәкәрләр арасында сораштыру үткәрү | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 2024 – 2026 еллар | Утырышлар саны | шартлы берәмлекләр | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - |
| **8 нче бурыч Хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру** | | | | | | | | | | | |
| 8.1. Түбәндәге мәсьәләләр буенча килешү буенча хокук саклау органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлек:<br>- өстенлекле илкүләм проектларны һәм республика программаларын гамәлгә ашырганда коррупциячел хокук бозуларны ачыклау буенча законнарның үтәлешен тикшерү;<br>- районның җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең законда каралган тыюлар һәм чикләүләрне үтәү тәртибен үтәүләрен тикшерү. Тикшерү нәтиҗәләрен киң игълан итү;<br>- эшмәкәрлек, ТКХ, бюджет чаралары, дәүләт һәм муниципаль милек белән эш итү субъектлары тарафыннан коррупциячел фактларны ачыклау һәм ачу;<br>- ачыкланган җинаятьләр категорияләре, коррупциягә дучар ителгән тармаклар, җинаять җаваплылыгына тартылган вазыйфаи затлар буенча аналитик материаллар нәтиҗәләре;<br>- коррупционерларны фаш итү, вазыйфаи затларны алар билгән вазыйфалардан читләштерү, гаепләләрне җаваплылыкка тарту фактлары турында мәгълүмат чаралары аша район халкына хәбәр итү;<br>- бюджет акчаларын тотканда законнарны һичшиксез үтәүгә юнәлдерелгән муниципаль | Арча районы прокуратурасы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге | 2024 – 2026 еллар | Дәүләт программасында каралган контроль тикшерүләрне гамәлгә ашыру тулылыгы, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| контроль органнары белән хезмәттәшлек итү | | | | | | | | | | | |
| **9 нчы бурыч Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны көчәйтү** | | | | | | | | | | | |
| 9.1. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналарын белем бирү оешмаларында законсыз акча җыю очраклары булганда гамәлләр турында белешмәлекләр белән тәэмин итү | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ | 2024 – 2026 еллар | Мәгариф оешмаларында законсыз акча җыю очраклары турында белешмәлекләр алган мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналары өлеше, процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 9.2. Граждannar муниципаль хезмәт вазыйфасына кергәндә барлыкка килә торган коррупциячел куркынычларны бетерү максатларында муниципаль хезмәт өлкәсендә закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү | җирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Бер елга планлаштырылган чараларның гомуми саныннан көнкүреш коррупциясен киметүгә юнәлдерелгән үткәрелгән чараларның өлеше, , процент | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - |
| 9.3. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның электрон чират нигезендә балалар бакчаларына керү чиратын саклауны тәэмин итү. Чиратны бозу мөмкинлеген искәртү. Татарстан Республикасы Арча МР мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында җыю процессына ай саен мониторинг уздыру | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ | 2024 – 2026 еллар | | процент | | | | | - | - | - |
| 9.4. Тормыш эшчәнлегенең социаль-икътисади тармакларында коррупция чагылышлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләренә мониторинг ясау | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» МУ, «Арча РУХ» ДАССУ | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 9.5. Медицина, мәгариф хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә коррупция күренешләре мәсьәләләре буенча медицина, мәгариф оешмаларында социологик сораштырулар үткәрү. Арча МР рәсми сайтында сораштыру нәтиҗәләрен урнаштыру | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» МУ, «Арча РУХ» ДАССУ | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 9.6. Татарстан Республикасы Арча һәм Әтнә районнарының хәрби комиссариатында коррупциягә каршы көрәш комиссияләренең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү, шул исәптән | Татарстан Республикасы Арча һәм Әтнә районнары хәрби | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| аларның эшчәнлегенә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү юлы белән | комиссариаты | | | | | | | | | | |
| 9.7. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | жирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 9.8. Җирле үзидарә органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен оештырылган оешмаларда коррупцияне кисәтү буенча эш оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру | жирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 9.9. Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу турында закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү | жирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 9.10. Районның муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлары тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен, шул исәптән алар үтәлмәгән очракта, аларны җаваплылыкка тартуны тикшереп торуны гамәлгә ашыру | жирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | | | | | | | - | - | - |
| 9.11 Ведомство карамагындагы оешмалар җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салуга кагылышлы ведомство карамагындагы оешмалар уставлары һәм хезмәт килешүләре таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, шул исәптән әлеге таләпләр үтәлмәгән очракта, затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү | жирле үзидарә органнары | 2024 – 2026 еллар | Ведомство карамагындагы оешмаларның гомуми саныннан үткәрелгән тикшерүләр саны | | | | | | - | - | - |
| Арча муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән Программа буенча барлыгы | | | | | | | | | | | 240,0 мең сум |